РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.09.2018 г. № 67

Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитетының
2018 елның 15 мартында 11 нчы номер белән расланган
“Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү
өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү
Административ регламентын раслау турында” карарына
үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 2018 елның 10 сентябрендәге 02-01-20-18 нче номерлы хаты нигезендә, Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ИТТЕ:

1. Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 15 мартында 11 нчы номер белән расланган “Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерүөчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 һәм 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

“8) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирүнең срогы яки тәртибе бозылу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктатып тору федераль законнар һәм аларга яраклаштырып кабул ителгән Рәсәй Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Рәсәй Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары һәм законнары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта, әгәр күпфункцияле үзәккә Федераль законның 16 нчы матдәсе, 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәленә (гамәл кылмавына) һәм карарларына судка кадәр(судтан тыш) шикаять бирү мөмкин.”

Эзмә авыл җирлеге башлыгы: А.Р.Шайхетдинов